ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

6 декабрь, 2023 ел № 28/6

Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм файдалану Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/12 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм файдалану Тәртибенә (Шәһәр Советының 2022 елның 23 июнендәге 15/8 номерлы Карары редакциясендә), 4 пунктны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Шәһәр Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турындагы карары белән түбәндәге шәһәр бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләменнән ким булмаган күләмдә раслана:

1) җирле бюджетка хисаплана торган автомобиль бензинына, турыдан-туры куылган бензинга, дизель ягулыгы, Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләре өчен мотор майларына акцизлардан;

2) торак пунктларның гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен капиталь ремонтлауга һәм ремонтлауга, күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендәге керемнәрдән;

3) гомуми файдаланудагы җирле (муниципаль) әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә физик һәм юридик затлардан, шул исәптән ирекле иганәләрдән, кире кайтарылмый торган кертемнәрдән;

4) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөк транспорты китерә торган зыянны каплау исәбенә шәһәр бюджетына керемнәрдән;

5) авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт белән хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан шәһәр бюджетына керемнәрдән.

Муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме, фактта хисап финанс елында кергән һәм аны төзегәндә фаразланган шәһәр бюджеты керемнәре күләме арасындагы аерманы исәпкә алып, чираттагы финанс елында үзгәртелергә тиеш.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ